ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУРАКАЙ АВЫЛЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

423746, Чуракай авылы,
Совет ур.,69нчы йорт.
Тел.:(85552)3 44 65;
E-mail: chrk.akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЧУРАКАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423746, село Чуракаево,
ул. Советская, дом 69. Тел.:(85552)3 44 65
E-mail: chrk.akt @yandex.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№8**

**24.04.2024**

Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Чуракай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында» 20.03.2020 ел, № 6 (28.02.2025 ел № 6 үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Чуракай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Башкарма комитетының 20.03.2020 ел, № 6 (28.02.2025 ел № 6 үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Чуракай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.6 пунктыннан түбәндәге эчтәлекле абзацны төшереп калдырырга:
"Салым чыгымнары кураторы тарафыннан бирелгән ташламаларның түләүчеләр тарафыннан таләп ителүен бәяләүне уздыру максатларында әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән ташлама кирәк дип таныла торган чагыштырманың минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин.".

1.2. 3.9_1 пунктын төшереп калдырырга.

1.3. 3.10_1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3.10_1. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль берәмлекнең техник салым чыгымнарына карата үткәрелми.»
3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Та-

тарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтындагы "Авыл җирлекләре" бүлегендә түбәндәге адрес буенча http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Р.Хайдаров